**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына үзгәреш кертү турында**

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе субъектларында ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссияләр турында» 2001 елның 28 декабрендәге 1500 номерлы Указы нигезендә **карар бирәм**:

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия турында» 2002 елның 31 гыйнварындагы ПУ-66 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2004 елның 19 июлендәге ПУ-479 номерлы, 2010 елның 11 гыйнварындагы ПУ-5 номерлы, 2010 елның 21 июлендәге ПУ-474 номерлы, 2010 елның 2 сентябрендәге ПУ-586 номерлы, 2011 елның 2 апрелендәге ПУ-181 номерлы, 2011 елның 5 октябрендәге ПУ-626 номерлы, 2013 елның 7 мартындагы ПУ-208 номерлы, 2013 елның 16 декабрендәге ПУ-1234 номерлы һәм 2017 елның 20 июлендәге ПУ-637 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составына, аны кушымтада бирелүче яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2020 ел, 27 гыйнвар
№ ПУ-29

Татарстан Республикасы
Президентының
2020 елның «27» гыйнварындагы
ПУ-29 номерлы Указына
кушымта

**Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре буенча комиссия составы**

| | |
|---|---|
| Тарханов<br>Илдар Габделхак улы | юридик фәннәр докторы, профессор, Казан (Идел буе) федераль университетының юридик факультеты фәнни җитәкчесе, комиссия рәисе (килешү буенча) |
| Глухова<br>Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы Президентының Дәүләт-хокук идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Әмиров<br>Кафил Фәхразый улы | «Связьинвестнефтехим» акционер җәмгыяте директорлар советы рәисе киңәшчесе (килешү буенча) |
| Вәлиева<br>Зилә Рәхимҗан кызы | Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе, «Татарстан хатын-кызлары» төбәк иҗтимагый оешмасы рәисе (килешү буенча) |
| Вәлиев<br>Револь Миргалим улы | юридик фәннәр докторы, Казан (Идел буе) федераль университетының халыкара һәм Европа хокукы кафедрасы профессоры (килешү буенча) |
| Гайнетдинов<br>Азат Галимҗан улы | «Социаль тернәкләндерү һәм җайлашу үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасы генераль директоры, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасы (килешү буенча) |
| Дәүлиев<br>Рафаил Гани улы | Җәзаларны үтәтү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе башлыгы ярдәмчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Забегина<br>Татьяна Вениаминовна | «Эбиволь» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте директоры, Россия Федерациясе Иҗтимагый палатасы әгъзасы, Татарстан Республикасы Сәүдә-сәнәгать палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Заһидуллин<br>Рөстәм Илдус улы | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Ногманов<br>Рафил Габдерафыйк улы | «Таттелеком» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры киңәшчесе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Сабурская<br>Сәрия Харис кызы | Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (килешү буенча) |
| Сәлимов<br>Венер Асылгәрәй улы | «Генераллар советы» Россия дәүләтчелеген ныгытуга булышлык итү буенча Татарстан республика иҗтимагый оешмасы идарәсе рәисе (килешү буенча) |
| Сергеева<br>Гөлнара Илдус кызы | «Бизнес коррупциягә каршы» иҗтимагый процедуралар үзәге» автоном коммерциячел булмаган оешмасының административ һәм гражданлык юнәлешләре буенча рәистәше, адвокат (килешү буенча) |
| Чашин<br>Александр Михайлович | Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Чубаров<br>Александр Анатольевич | Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты, Татарстан Республикасы Дәүләт Советының Законлылык һәм хокук тәртибе комитеты рәисе урынбасары (килешү буенча) |
| Шәрифуллин<br>Рамил Әнвәр улы | «Россия суд эшчәнлеге дәүләт университеты» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры (Казан шәһәре) (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шәрифуллин Риф Камил улы | Татарстан Республикасы Югары Суды Рәисенең отставкадагы урынбасары (килешү буенча) |